Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2022 елның 27 апреле №50

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 18 декабрендәге 89 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясы һәм «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе турында» Россия Федерациясе Югары Советы карарының һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең (2021 елның 11 июнендәге үзгәрешләр белән) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта барлык хокук ияләренең ризалыгы, блокланган төзелеш йортының бер рәтендә барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы;

2). 36 статьяның 7 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

2. Әлеге карарны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе: В.П. Никитин